**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**17.07. 2023 ел** **№ 929**

**«Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Предметы Биектау муниципаль районы муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү булган муниципаль контрактларны банк озатуын гамәлгә ашыру очракларын билгеләү турында» 2023 елның 22 февралендәге 308 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Контрактларны банк белән озатуны гамәлгә ашыру турында" 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карарына туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Предметы Биектау муниципаль районы муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү булган муниципаль контрактларны банк озатуын гамәлгә ашыру очракларын билгеләү турында» 2023 елның 22 февралендәге 308 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Банк уздыруда төзелә торган контрактны тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) яки заказчы тарафыннан җәлеп ителгән банк белән озатуга, 200 млн. сумнан ким булмаган контрактны үтәү кысаларында исәп-хисаплар мониторингына карата.»;

-1.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кабул ителә торган товарларның, эшләрнең (аларның нәтиҗәләренең), хезмәт күрсәтүләрнең 500 млн. сумнан ким булмаган контракт шартларына туры килүен тәэмин итәргә мөмкинлек биргән хезмәтләр күрсәтү максатларында тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) яисә банкның заказчысы тарафыннан җәлеп итүне күздә тоткан контрактны банк белән озатуга карата.»

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин